УДК 372. 882 DOI: 10.22378/he.2018-3-1.158-167

# ОКТЯБРЬ РЕВОЛЮЦИЯСЕННӘН СОҢ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ МӘСЬӘЛӘСУ (ХХ ГАСЫРНЫҢ 20–30нчы ЕЛЛАРЫ)

***А.М. Сафина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*aliyasafina17@yandex.ru*

Мәкаләдә татар әдәбиятын XX гасырның егерменче-утызынчы еллар аралыгында укыту мәсьәләсенә күзәтү ясала. Октябрь революциясеннән соң, беренче һәм икенче баскыч мәктәпләрдә татар әдәбиятын төрле юнәлешләр ярдәмендә өйрәтүгә әһәмият бирелә. Әлеге чорда татар әдәбиятын укыту буенча кулланылышта булган программаларга һәм дәреслекләргә анализ тәкъдим ителә.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, совет мәктәбе, укыту, программалар, егерменче-утызынчы еллар, дәреслекләр

1917 елгы октябрь революциясе илнең сәяси һәм икътисади тормышын, халыкның мәдәниятен үзгәртүдә кискен борылыш ясый. Әлеге үзгәрешләр мәгариф системасын да тамырдан яңартуны максат итеп куя. Бу елларда уку-укыту системасында түләүсез һәркем белем ала алырлык бердәм дөньяви мәктәп оештыру төп максаты итеп куелып, мәктәпләр челтәрен тирәннән үзгәртеп кору буенча җитди чаралар күрелә башлый. Гыйльми һәм уку-укыту йортлары белән турыдан-туры идарә итү, шулай ук аерым мәгариф органнары арасындагы төрле мәсьәләләрне хәл итү максатыннан Мәгариф халык комиссариаты төзелә. Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Советының 1918 елда чыккан «РСФСРның бердәм эш мәктәбе турындагы» декрет [11, с. 133–137] һәм «Бердәм эш мәктәбенең төп принциплары турында» карар [11, с. 137–145] совет мәктәбендә белем бирүнең яңа системасының асылын билгели. Әлеге документлар нигезендә уку йортлары, югары уку йортларыннан башка, барысы да «бердәм эш мәктәбе» дип йөртелә башлый. Бердәм эш мәктәбе гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирү, I һәм II баскыч мәктәпләр оештыру, укучыларны фән нигезләре белән таныштыру, укытуны хезмәт белән бәйләп алып бару кебек бурычларны алга куя. Совет мәктәбе бу чорда гомуми белем бирү мәктәбе генә түгел, ә хезмәт мәктәбе дә булып тора. Башка

фәннәрне өйрәнү белән беррәттән, мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүгә дә басым ясала башлый, чөнки Октябрь революциясенә кадәр татар әдәбияты күпмедер вакыт аерым укытылмый. Татар әдәбиятын мәктәпләрдә укытуның төп максаты – әсәрне уку һәм анализлау ярдәмендә укучы аны аңларга, күзалларга омтылудан гыйбарәт. Әдәбият аша укучы башкаларга игътибарлы булырга, кеше күңелен яраламаска, җәмгыятьтә үз урынын табарга өйрәнә. Нәтиҗәдә, балада һәр нәрсәгә карата үз фикере, үз карашы булдырыла.

Мәктәпләрдә татар әдәбиятын укытуда әлеге бурычларны тормышка ашыру өчен яңа эчтәлекле уку китаплары, дәреслекләр, методик кулланмалар кирәклеге мөһим алшартларның берсе була. Егерменче еллар башында совет мәктәпләрен төрле предметлар буенча, шул исәптән татар әдәбиятыннан да, дәреслекләр белән тәэмин итү мәсьәләсе актуаль проблемаларның берсенә әверелә. Әлеге мәсьәләне чишүдә III Бөтенроссия татар укытучылары съезды (1918) [19, с. 17] һәм тел мәсьәләләренә багышланган Бөтенроссия конференциясе (1919) дә зур этәргеч ясый. Нәтиҗәдә, сәяси һәм методик яктан югары сыйфатлы дәреслекләр һәм методик кулланмаларны тиз арада бастырып чыгару төп бурычларның берсе итеп куела. Чөнки алар укучы һәм укытучы эшчәнлеген бәйләүче, берләштерүче төп кораллар һәм бары тик алар ярдәмендә генә белем һәм тәрбия бирүне максатчан, эзлекле итеп алып барырга мөмкин. Ләкин югары сыйфатлы программаларны, дәреслекләрне тиз арада төзеп, бастырып чыгару мөмкин хәл булып чыкмый. Дәреслек-программаларның, методик кулланмаларның яңалары төзелгәнче, Октябрь революциясенә кадәр язылган уку китапларының уңышлылары [7] аерым төзәтмәләр, үзгәрешләр белән яңадан басылып, файдалану өчен мәктәпләргә тәкъдим ителәләр. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның 1919 елда яңадан тулыландырылып басылып чыккан «Яңа әдәбият» китабында идея-эстетик яктан искергән яки сәнгати яктан түбән булган әсәрләрдәге өзекләр әлеге чорны яктыртуга якын торганы белән алмаштырыла.

Яңа программалар, уку планнары төзү, уку-укыту китаплары, дәреслекләр язу, педагогик журналлар чыгару һ. б. әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү максатыннан, 1921 елда Мәгариф Халык Комиссариаты карамагында Гыйльми һәйәт (соңрак Гыйльми үзәк, Академик үзәк) оештырыла [17, 3 б.]. Әлеге үзәк тарафыннан мәктәпләр өчен яңа дәреслекләр, яңа программалар, уку планнары төзү, төрле курслар ачу, педагогик журнал чыгару кебек иң әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү максат итеп куела. Шулай ук әлеге үзәк алдына республиканың барлык төр уку йортлары өчен дәүләт гыйльми совет программаларын һәм планнарын җирле үзенчәлекләргә туры китерү бурычы йөкләнә. Татар теле һәм әдәбияты буенча дәреслекләр, уку әсбаплары эшләү өчен авторлар коллективы оештырыла. Коллектив тарафыннан педагогик һәм гыйльми яктан эшләнелеп, заманга җавап бирердәй дәреслекләр булдыру төп бурыч итеп куела. М. Корбангалиев, Г. Ходаяров, Ф. Сәйфи, Х. Бәдигый, Г. Ибраһимов һ. б. авторлар ярдә-

мендә беренче һәм икенче баскыч мәктәпләр өчен программалар төзелә һәм дәреслекләр языла.

1917–1922 еллар аралыгында мәктәпләрдә татар әдәбияты Октябрь революциясенә кадәрге традициягә таянып һәр мәктәпнең үзе яки район мәгариф бүлеге җитәкчелегендә төзелгән кулъязма программалар буенча укытыла. 1922 елда Академик үзәк тарафыннан, эзләнү һәм табышларның бер дәверен чагылдырып, татар теле һәм әдәбиятын укыту буенча программа төзелә [5]. Программада татар теле һәм әдәбияты аерым түгел, ә бер үк фән рәвешендә тәкъдим ителә. Әлеге программада методик алымнар шактый киң яктыртыла һәм аларның күбесе уңышлы дип табыла. Алар арасында сәнгатьле укуга аеруча зур урын бирелә. Моннан тыш укылган текст буенча эчтәлек сөйләү, хикәя язу, сораулар кую, җаваплар бирү, план төзү, әсәр геройларының холык-фигыльләрен билгеләү һ. б. алымнар актив кулланыла. Бу методик алымнар әсәр эчтәлеген аңлап үзләштерүгә һәм укучыларның фикерләү сәләтен үстерүгә юнәлтелә. Әлеге программа 1928 елга кадәр мәктәпләрдә киң кулланылыш ала. Шулай да реферат, хикәя яздырту, лекцияләр тыңлату, укылган әсәрнең темасын билгеләтү һ. б. шундый алымнар башлангыч сыйныф укучылары өчен авыр булуы программаның җитешсез ягы дип искәртелә [14, 56 б.].

1923 елдан мәктәпләрдә комплекслы укыту ситемасы килеп керә. Әлеге система тел, әдәбият, тарих, география һ. б. фәннәрне аерым укытуны хупламый, ә барлык фәннәрне комплекс хәлендә карауны алга куя. Комплекслы укыту сыйныф-дәрес системасын юкка чыгара. Укыту дәүләт гыйльми совет тарафыннан төзелгән «комплекслы программалар» ярдәмендә алып барыла. Әлеге программалар эчтәлеге ягыннан гына түгел, хәтта төзелеше ягыннан да алдагыларыннан бик нык аерыла. Дәүләт гыйльми совет программаларының төп юнәлеше булып белем бирүне иҗтимагый фәннәр ярдәмендә өйрәтү тора. Бу система татар әдәбиятын укытуны да арткы планга күчерә, ягъни уку планнарында фән буларак үз урынын бөтенләй таба алмый. Татар әдәбияты теге яки бу һөнәрне үзләштерүдә иллюстрация ролен үтәүче итеп кенә тәкъдим ителә, җәмгыятьне өйрәнү фәненең билгеле бер өлеше буларак кына карала.

Комплекслы укыту системасы белән берлектә яңа укыту методлары һәм алымнары да килеп керә. XX гасыр башында Америкада кулланылынган Дальтон-план методы егерменче елларда совет мәктәпләрендә лаборатор-бригада исеме белән кулланыла башлый. «Лаборатор-бригада» методы дәрес структурасын, укытучының әңгәмә ярдәмендә фәннәрне өйрәнү, белем алу системасын кире кага. Укучылар бригадаларга бүленеп, лаборатория системасында күмәкләшеп эшләүгә әһәмият бирә. Билгене укытучы бригаданың җитәкчесе (сайлап алынган укучы) тарафыннан телдән яки язма рәвештә ясалган нәтиҗәләрдән чыгып куя. Әлеге метод укучыларны үзлекләреннән эшләргә өйрәтсә дә, күп очракта һәрбер укучының эшчәнлек дәрәҗәсе тиешенчә дөрес бәяләнми, кайбер укучыларның активлыгы күренми кала. Шулай ук бу система укытучының да ролен киметә, укыту-

чы читтән күзәтеп торучы, киңәш биреп торучы булып кына кала. Бу методка нигезләнеп язылган татар әдәбиятын укыту программаларында [9; 15;16] әдәбият җәмгыятьне өйрәнү фәненең бер өлеше буларак кына бирелә, ягъни иҗтимагый теманы өйрәнгәндә әдәбият иллюстратив материал булып кына хезмәт итә һәм укучыларда индивидуаль эшләү, үз фикереңне җиткерү кебек алымнар арткы планга кала.

Әлеге программаларга таянып әдәбияттан чор таләпләренә җавап бирерлек эш китаплары һәм дәреслек-хрестоматияләре дөнья күрә башлый. Шулар арасында «Азат мәктәп» [2], «Ташкын» [18] дәреслек-хрестоматияләр башка уку китапларыннан уңай якка аерылып торулары белән отышлы. Чөнки әлеге уку әсбаплары комплекс ысулына туры китереп төзелүе белән аерылып торалар. Мәсәлән, «Азат мәктәп» дәреслек-хрестоматиясен төзүче авторлар китапның кереш өлешендә әлеге хезмәтнең комплекс ысулына туры китереп эшләнүе, китапка заманга яраклы итеп язылган әдәби әсәрләр кертелүе белән әһәмиятле дип ассызыклыйлар [2, 5 б.]. Дәреслектәге бүлекләр дә «Авыл», «Шәһәр», «Хәзерге заман» дип исемләнеп, әдәби әсәрләр дә шул тематикага яраклаштырылып сайлана. Педагогиканың билгеледән билгесезлеккә таба бару принцибы әдәбият дәресләрендә әлеге хрестоматиядә чагылыш таба. «Ташкын» дәреслек-хрестоматиянең төзелү принцибы «Азат мәктәп»тәге кебек хәзерге әдәбияттан элеккеге мирас әдәбиятына таба алып барыла. Бүлекләр дә шулай ук «Яңа чор», «Хәзерге шәһәр», «Хәзерге авыл» дип аталып йөртелә. Комплекслы темалар итеп «Крестьяннар тормышы», «Татар әдәбиятында муллалар тормышы», «Хатын-кыз мәсьәләсе» кебек мәсьәләләр тәкъдим ителә. Мондый тематик бүленеш әдәбиятның идея эчтәлеген үзләштерүне алгы планга куйса да, әдәби әсәрнең кыйммәтенә игътибар бирелми, ә әдәби текстның җәмгыять белеме темаларына караган өлеше генә файдаланыла. Тәкъдим ителгән әлеге дәресләк-хрестоматияләр шул чорны тасвирлаган әдәби әсәрләргә игътибар бирелүе белән отышлы була. Ләкин бу уку китаплары педагогик һәм методик таләпләргә җавап биреп бетерми, ә әдәби текстлар җыентыгы булып кына кала [4, 129 б.].

1926нчы елның ахырларында комплекслы укыту системасы уңышсыз дип табыла. Әдәбият галиме Г. Сәгъди дә моның тискәре ягы дип: беренчедән, укытучыларның да, укыту методларының да әһәмияте югалуы, икенчедән, әдәби әсәрләргә, китапка карата кызыксыну кимү дип ассызыклый [6, 60 б.].

Татар әдәбиятын укыту буенча 1927 елга кадәр программалар, дәреслекләр булса да, алар бары тик аерым теманы өйрәнгәндә өстәмә кулланма ролен генә үти. 1927 елда Казанда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының I Бөтенсоюз конференциясендә татар телен һәм әдәбиятын укыту, уку программалары һәм дәреслекләр төзү мәсьәләләре карала. Татар әдәбиятын совет мәктәпләрендә укытуның төп бурычлары булып коммунистик рухта тәрбия бирү һәм коммунизм җәмгыятен төзүчеләрне хәзерләү тора [3, 147 б.]. Конференциядә тәкъдим ителгән карарлар нигe-

зендә, Мәгариф Халык Комиссариаты тарафыннан барлык фәннәр буенча программалар төзелә башлый. Алар барлык мәктәпләр өчен дәүләт программалары булып торалар. 1928 елда Мәгариф Халык Комиссариаты раславында, М. Фазлуллин тарафыннан «II баскыч мәктәпләре өчен ана теле һәм әдәбияты программасы» дөнья күрә [8]. Әлеге программа мәктәптә әдәбият фәнен предмет итеп укытуны юлга салуда зур роль уйный. Әдәбият фәнен укыту буенча дөрес юнәлеш бирүче әлеге дәүләт документы яшь буынга белем һәм тәрбия бирү ягыннан аеруча әһәмиятле. Әмма шул чор таләпләренә җавап бирә алырлык ныклы әдәби белем бирүне тәэмин итә алмау, укучыларга үзләштерү өчен авыр булган әсәрләрне программага кертү, әдәбиятның тәрбияви мөмкинлекләре, укыту алымнары ачык яктыртылмау бу программаның җитешсезлеге дип искәртелә. Шулай да, программаның фәнни һәм методологик структурасы яңа төзеләчәк программаларның нигезен тәшкил итә.

Утызынчы еллар башында совет мәгарифенә проект методы килеп керә. Әлеге метод Америкада XX гасырның беренче яртысында америка фәлсәфәчесе һәм педагогы Дж. Дьюи тарафыннан кулланылышка кертелә. Бу метод аерым фәннәрне юкка чыгара, сыйныфлар, расписаниеләр бетерелә. Дәресләр я лаборатор эш, я әдәби экскурсия төсендә кырларда, фермаларда, завод-фабрика цехларында уздырыла. Укучылар көнкүреш хезмәт белән бәйле биремнәрне үтәргә тиеш булалар. Схема ясау, сызым сызу, проектлар төзү процессы вакытында балалар математика, физика, химия, сызым кебек фәннәр буенча тулы белемнәр алырга тиеш булалар. Нәтиҗәдә укытуның бу формасы бер фәнне дә тулаем алып өйрәнүне максат итеп куймый. Әлеге форма мәктәптә татар әдәбиятын укытуда да чагылыш таба. Бу елларда төзелгән программаларда укучыларга әдәби әсәрнең иҗтимагый тормыш, сыйнфый көрәш белән бәйле темаларны яктырткан өлешләре генә тәкъдим ителә, тулаем әдәби әсәр өйрәнелми [10].

1930 еллардан соң уку-укыту системасы янәдән үзгәрешләр кичерә башлый. Бу үзгәрешләр татар әдәбиятын укытуда да чагылыш таба. 1931 елның августында ВКП(б) Үзәк Комитеты «Башлангыч һәм урта мәктәп турында»гы һәм 1932 елны «Башлангыч һәм урта мәктәптә укыту программалары һәм режимы турында»гы карарлар [14, с. 156–164] совет мәктәбе эшенең сыйфатын күтәрүдә әһәмиятле роль уйныйлар. Бу документлар нигезендә СССР халыкларының милли әдәбиятларына, сәнгатьләренә караган материалларны әдәбият дәреслегенә кертеп, программа һәм дәреслекләрне укучыларга белем һәм тәрбия бирерлек итеп төзергә кирәк кебек бурычлар куела. Әлеге елларда татар әдәбиятын укытуны, әдәби әсәрләр өйрәнүне укыту программаларын кире кайтару, әдәби текстларны тәрбия максатында файдалану кебек юллар ярдәмендә алып барыла башлый. Уку процессының нигезен бу елларда сыйныф-дәрес системасы белән алып барыла. Дәрес һәркөнне бер калыпка салынып эшләнгән нигездә алып барыла, мөстәкыйль эш алымнары куллану мөмкинлекләре юкка чыга.

«Башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен дәреслекләр турында»гы 1933 елның февралендә чыккан карар нигезендә һәр предмет буенча Мәгариф Халык Комиссариаты тарафыннан расланган бердәм мәҗбүри дәреслекләр буенча гына укытырга рөхсәт ителә. [11, с. 164–165]. Шуның нәтиҗәсендә мәктәп программалары үзгәртелеп төзелә, яңа стабиль дәреслекләр дөнья күрә. Әдәбият буенча Г. Нигъмәти, Г. Гали, Б. Яфаровлар төзегән программада [20] әсәрләрне, тәрбия ягыннан әһәмияте кимемәсен өчен, бөтен көенчә өйрәнергә кирәк дигән фикер алга куела. Бу программа проектлар методы һәм лаборатор-бригада системасы белән бәйләнешләрен тулысынча өзә, укучыларга әдәбияттан ныклы һәм эзлекле белем бирү, укыту процессында балаларны интернациональ яктан тәрбияләү зарурлыгы мәсьәләләрен күтәреп чыга. Бу елларда төзелгән программалар нәтиҗәсендә һәрбер класс өчен татар әдәбиятыннан дәреслек-хрестоматияләр дөнья күрә [1; 12; 13].

Октябрь революциясеннән соң, егерменче-утызынчы еллар арасында мәктәптә татар әдәбиятын укыту төрле юнәлештә алып барыла. Совет мәктәбе оешкан елларда татар әдәбияты дәресләрдә ярдәмчел вазифаны гына үтәсә, утызынчы елларда исә ул аерым предмет булып өйрәнелә башлый. Егерменче елларда татар әдәбиятын укыту буенча дәреслекләр, уку кулланмалары төрле булулары белән аерылып тора. Яңа дәреслекләр белән бер үк вакытта үзгәртелеп язылган революциягә кадәрге дәреслекләр дә гамәлдә була. Утызынчы елларда исә, бердәм нормага туры китерелгән һәм бер стандартка салынган мәктәп дәреслекләре урын ала. Шулай ук илдә барган төрле үзгәрешләр (татар алфавитын гарәп графикасыннан яңалифкә (латинга), соңрак рус алфавитына (кирилицага) күчү татар әдәбиятын укытуга да тискәре йогынты ясамый калмый. Егерменче еллар уртасында латин алфавитына нигезләнгән яңалиф язу системасы рәсми рәвештә татар язуы итеп гамәлгә кертелә. Әлеге борылыш гарәп шрифтында язылган дәреслекләрдән формасы белән дә, эчтәлекләре ягыннан да аерылып торган латинлаштырылган уку китаплары тууга китерә. Бу елларда мәктәптә татар әдәбиятын укытуга түгел, ә латинча укырга өйрәтүгә күбрәк басым ясала. Гарәп шрифтында булган күп кенә әдәби әсәрләр, дәреслекләр, кулъязмалар кулланылыштан төшеп калына. Утызынчы еллар азагында латинлаштырылган татар алфавиты яңа рус графикасына нигезләнгән алфавитка алыштырыла, кабат укыту мәсьәләсе күтәрелеп чыга. Соңгы унъеллыкта латин язуында басылган дәреслекләрнең әһәмияте югала. Әлеге үзгәрешләр мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүгә дә күпмедер дәрәҗәдә тоткарлыклар тудыра.

## ӘДӘБИЯТ

1. Агишев Я., Хаҗиев В. Әдәбият. Тулы булмаган урта мәктәпнең VI классы өчен дәреслек. Казан: Татгосиздат, 1938. 67 б.

2. Азат мәктәп. Беренче баскыч мәктәпләрнең ахыргы сыйныфлары, совпартшколалар һәм педтехникумнар өчен / төз. Г. Нигъмәти, Ш. Саттаров, М. Мансур. М.: Нәшрият, 1927. 399 б.

3. Бөтенсоюз күләмендә беренче мәртәбә җыелган төрек-татар теле һәм әдәбият укытучылары конференциясе. Беренче тел-әдәбият конференциясе материаллары. Казан, 1927. 199 б.

4. Вәзиева Җ. Совет мәктәпләрендә әдәбият дәреслекләре // Вопросы татарской литературы. Ученые записки КГПИ. Казан, 1972. Вып 106. Б. 116–133.

5. Дүрт еллык беренче баскыч берләшкән эш мәктәпләре өчен программа. Уфа: Башпром мәтабгасы, 1922. 41 б.

6. Заһидуллина Д. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. Казан: Мәгариф, 2000. 335 б.

7. Ибраһимов Г. Яңа әдәбият. Казан: Сабах, 1919. 224 б.

8. Икенче баскыч мәктәпләре өчен ана теле һәм әдәбияты программасы /төз. М. Фазлуллин. Казан, 1928. 59 б.

9. Икенче баскыч татар һәм башкорт мәктәпләре өчен /төз. В. Хангильдин, С. Ямалиев. Казан, 1926. 36 б.

10. Колхоз яшьләре мәктәпләре өчен ана теле һәм әдәбияты программасы / төз. М. Фазлуллин. Казан: Татиздат, 1930. 56 б.

11. Народное образование в СССР. Сборник документов 1917–1973 гг. М.: Педагогика, 1974. 560 с.

12. Нигъмәти Г. Әдәбият. Урта мәктәпләр өчен дәреслек. 5 нче уку елы. Казан: Таттосиздат, 1933. 254 б.

13. Нигъмәти Г., Яфаров Б. Әдәбияттан хрестоматия. XIX һәм XX йөз башы. Тулы булмаган урта мәктәпләр өчен дәреслек. Казан: Таттосиздат, 1934. 303 б.

14. Нигъмәтуллин Ә. Урта мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: Татар.кит.нәшр., 1983. 232 б.

15. Программалар. Казан педагогия техникумының беренче курслары өчен /төз. Х.Бәдигый. Казан, 1925. 73 б.

16. Программалар. Өч еллык крестьян мәктәпләре өчен /төз. М. Фазлуллин. Казан, 1926. 73 б.

17. Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда / рекол.: Ф. Солтанов, М. Гыйбатдинов, Л. Мортазина. Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. 2 т. 486 б.

18. Ташкын: әдәби хрестоматия. Икенче баскыч мәктәп, техникумнар һәм башка урта дәрәҗәдәге уку йортларына дәреслек итеп тәкъдим итеlә /төз. С. Борһан, Г. Нигъмәти, Ф. Әмирхан. Казан, 1928. 226 б.

19. Тутаев М. Развитие народного образования в Татарии (1917–1940). Казань, Тат. кн. изд-во. 1975. 204 с.

20. Урта мәктәп өчен әдәбият программасы / төз. Г. Нигъмәти, Г. Гали, В. Яфаров. Казан: Таттосиздат, 1933. 18 б.

**Автор турында белешмә:** Сафина Алия Мәгъсүм кызы – филология фәннәре кандидаты, фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7А, Казан, Россия Федерациясе); aliyasafina17@yandex.ru

*Сафина А.М.* Октябрь революциясеннән соң татар әдәбиятын укыту мәсьәләсе (XX гасырның 20–30нчы еллары)

# ПРОБЛЕМА ПРЕПОДАВАНИЯ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ ПОСЛЕ ОКТЯБРЬСКОЙ РЕВОЛЮЦИИ (20–30-е гг. XX века)

***А.М. Сафина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*aliyasafina17@yandex.ru*

В статье рассматривается преподавание татарской литературы в 1920–1930-е гг. Освещаются разные направления в изучении татарской литературы в школах первой и второй ступеней после Октябрьской революции. Делается анализ некоторых программ и учебников по татарской литературе указанного периода.

**Ключевые слова:** татарская литература, советская школа, преподавание, программы, 1920–1930-е гг., учебники

**Для цитирования:** Сафина А.М. Октябрь революциясеннән соң татар әдәбиятын укыту мәсьәләсе (XX гасырның 20–30нчы еллары) // Историческая этнология. 2018. Т. 3, № 1. С. 158–167. DOI: 10.22378/he.2018-3-1.158-167

**Сведения об авторе:** Сафина Алия Магсумовна – кандидат филологических наук, научный сотрудник, Центр истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); aliyasafina17@yandex.ru

# PROBLEMS OF TEACHING TATAR LITERATURE AFTER THE OCTOBER REVOLUTION (20–30S OF THE 20TH CENTURY)

***A.M. Safina***

*Sh. Marjani Institute of History, Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*aliyasafina17@yandex.ru*

The article examines teaching Tatar literature in the 1920–1930s. Various directions in studying Tatar literature at schools of the first and second levels after the October revolution are highlighted. The author analyzes some Tatar literature curricula and textbooks of the given period.

**Keywords:** Tatar literature, curricula, teaching, text-books, 1920–1930s, Soviet school

**For citation:** Safina A.M. Problems of Teaching Tatar Literature after the October Revolution (20–30s of the 20th Century). *Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology*, 2018, vol. 3, no. 1, pp. 158–167. DOI: 10.22378/he.2018-3-1.158-167

## REFERENCES


1. Agishev Y., Khağiev B. *Ädäbiyat. Tuly bulmagan urta mäktäpneň 6 klassy öchen däreslek* [Literature. Textbook for the 6th class of Lower Secondary School]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1938. 351 p. (In Tatar)

2. *Azät mäktäp. Berenche baskych mäktäplärneň akhyrgy syynyflary, sovpartshkolalar häm pedtekhnikumnar öchen* [Independent School. For First Level Schools, Sports Schools and Pedagogical Schools]. Compl. by G. Nigmati, Sh. Sattarov, M. Mansur]. Moscow, Naschriyat Publ., 1927. 399 p. (In Tatar)

3. *Bötensoyuz külämendä berenche märtäbä ğyelgan törek-tatar tele häm ädäbiyät ukytuchylary konferentsiyase* [All-Union Conference of Turko-Tatar Languages and literature teachers. The language and literature conference materials]. Kazan, 1927. 19 p. (In Tatar)

4. Väzieva Ğ. Sovet mäktäplärendä ädäbiyat däreslekläre [Books Used in Teaching Literature in Soviet School]. *Voprosy tatarckoi literatury. Uchenye zapiski – Issues of the Tatar literature. Studies of the Kazan State Pedagogical Institute,* 1972, no. 106, pp. 116–133. (In Tatar)

5. *Dürt ellyk berenche baskych berläshkän esh mäktäpläre öchen programma* [The Curriculum for the First Level of Four-year Schools for the Workers]. Ufa, Bashprom mätabgasy Publ., 1922. 41 p. (In Tatar)

6. Zahidullina D. *Urta mäktäptä tatar ädäbiyatyn ukytu metodikasy*. [Methods for Teaching the Tatar Literature in School of Secondary Education]. Kazan, Magarif Publ., 2000. 334 p. (In Tatar)

7. Ibrahimov G. *Yaňa ädäbiyat* [New Literature]. Kazan, Sabah Publ., 1919. 224 p. (In Tatar)

8. *Ikenche baskych mäktäplär öchen ana tele häm ädäbiyaty programmasy* [The Tatar Language and Literature Curricula for the Second Level Tatar Schools]. Compl. by M. Fazlullin. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1928. 59 p. (In Tatar)

9. *Ikenche baskych tatar häm bashkort mäktäpläre öchen* [For the Tatar and Bashkir Schools of Secondary Education]. Compl. By V. Khangildin, S. Yamaleev Kazan, 1926. 36 p. (In Tatar)

10. *Kolhoz yash`läre mäktäpläre öchen ana tele häm ädäbiyaty programmasy* [The Tatar Language and Literature Curriculum for collective farms youth]. Coml. by M. Fazlullin. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1930. 56 p. (In Tatar)

11. *Narodnoe obrazovanie b SSSR: obsheobrazovatelnaya shkola: sbornik dokumentov 1917–1973 gg.* [Public Education in the USSR: General Education School: Collection of Documents in 1917–1973]. Compl. By A. Abakumov, N. Kuzin, I. Puzyrev, L. Litvinov. Moscow, Pedagogika Publ., 1974. 560 p. (In Russian)

12. Nigmati G. *Ädäbiyat. Urta mäktäplär öchen däresle* [Textbook for Secondary Education Schools]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1933. 254 p. (In Tatar)

13. Nigmati G., Yfarov B. *Ädäbiyattan hrestomatiya. XIX häm XX yöz bashy. Tuly bulmagan urta mäktäplär öchen däreslek* [The Literature Chrestomathy. 19$^{th}$ – early 20$^{th}$ Century. Textbook for Lower Secondary Schools]. Kazan, Tatgosizdat, 1934. 303p. (In Tatar)

14. Nigmatullin Ä. *Urta mäktäptä tatar ädäbiyatyn öyränüneň fänni-metodik nigezläre* [Scientific – Methodological Basis of the Study of the Tatar Literature at Secondary Education Schools]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1983. 232 p. (In Tatar)

15. *Programmalar. Kazan pedagogiya texnikumynyй berenche kurslary öchen* [School Curricula for the First Year Students of the Kazan Pedagogical College]. Compl. by H. Badigi. Kazan. Tatar Book Publ. House, 1925. 73 p. (In Tatar)

16. *Programmalar. Öch ellyk krestyan yaschläre mäktäpläre öchen* [Curriculum for the Rural Youth Three-Year Schools]. Compl. by M. Fazlullin. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1926. 73 p. (In Tatar)

17. *Tatar pedagogik fikere antologiyase* [Anthology of Tatar Pedagogical Thought]. Vol.1. Ed. By F.M. Soltanov, M.M. Gibatdinov, L.R. Mortazina. Kazan, Tatar Book Publ. House, 2014. 407 p. (In Tatar)

18. *Tashkyn: ädäbi khrestomatiyä* [Stream: the Literature Chrestomathy. Compl. by C. Burgan, G. Nigmati, F. Amirkhan]. Kazan, 1928. 226 p. (In Tatar)

19. Tutaev M. *Rasvitie narodnogo obrazabaniya v Tatarii* [The Development of the Public Education in Tatariya (1917–1940)]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1975. 204 p. (In Russian)

20. *Urta mäktäp öchen ädäbiyat programmasy* [Literature Curricula at School of Secondary Education]. Compl. By G. Nigmati, G. Gali, V. Yafarov]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1933. 18 p. (In Tatar)

**About the author:** Aliya M. Safina is a Candidate of Science (Philology), Research Fellow, the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History, Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); aliyasafina17@yandex.ru